РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » 01 2021 г. № 40

Ютазы муниипаль районы Башкарма комитетының 15.05.2020 ел, № 297 "Ютазы муниципаль районы муниципаль милегендә булган күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында" 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 18 декабрендәге 1148 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында" 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Ютазы муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында» Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 15 маендагы 297 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендатор 2020 елның 1 апреленә торышы буенча юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булган икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә.» ;

1.2. 3 пунктта:

- беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектерү тиешле вакыт өчен аренда түләве күләмендә ясала;».

2. Әлеге карар Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе С.П. Самонина

Огнева Е. С.
(85593)2-76-31